ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘКӘЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423749, Иске Телэкэй авылы,
Үзәк ур.,87 нче йорт.
Тел/факс 5-41-21

ТЛЯКЕЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423744, село Старое Тлякеево,
ул. Центральная, дом 87.
Тел/факс 5-41-21

**Карар** | **Постановление**

**«20» июнь 2019 ел** | **№15**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитетынын "14" январь 2019ел. № 1 "Запастагы гражданнарны хәрби исәпкә алуны оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1996 елның 31 маеннан "Оборона турындагы", 1998 елның 28 мартыннан "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт" турындагы, 1997 елның 26 феарленнән "Мобилизацион әзерлек һәм Россия Федерациясендә мобилизация" турындагы федераль законнарны үтәү максатыннан һәм 27.11.2006 елның 719 санлы "Хәрби хезмәт нигезләмәсе турында", Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запастагы гражданнарын , запастагы федераль башкарма хакимият органнарының һәм дәүләт хакимияте органнарында, авыл җирлеге органнарында һәм оешмаларда эшләүче гражданнарны броньлау буенча төп нигезләмәләр" турында Россия Федерациясе хөкүмәте карарын, үтәү максатларында Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитетының "14" январь 2019 ел 1 нче санлы «Запастагы гражданнарны хәрби исәпкә алуны оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Исеме

1.1.7. 111 бүлегенең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- «3.2. җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориясендә яшәүче гражданнарның яки вакытлыча яшәүче (3 айдан артык вакытка) беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга »;

1.2. Нигезләмәнең 111 бүлегенең 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- «3.8. Ел саен хәрби комиссариатка 15 яшькә җиткән ир - атлар һәм 16 яшькә җиткән ир-атлар һәм 16 яшькә җиткән гражданнар исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр-киләсе елда хәрби исәпкә беренчел куелырга тиешле ир-атлар исемлеген

хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән форма буенча тапшырырга кирәк;»;

1.3. Карарның 2 нче кушымтасының 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «17. Ел саен хәрби комиссариатка 15 яшькә җиткән ир - атлар һәм 16 яшькә җиткән ир-атлар һәм 16 яшькә җиткән гражданнар исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр-киләсе елда хәрби исәпкә беренчел куелырга тиешле ир-атлар исемлеген хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән форма буенча тапшырырга кирәк;»;

1.4. Карарның 2 нче кушымтасының 19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

- «19. Чираттагы чакырылыш башланыр алдыннан барлык призывникларга да характеристикалар бирергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Теләкәй авыл җирлеге хәбәрләре бүлегендә урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Теләкәй авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Р.Миннеханов

.